ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24 декабрь2021 ел** **№38**

**«Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 08 ноябрь 2021 №1, 10 ноябрь 2021 №2, 10 ноябрь 2021 №3, 10 ноябрь 2021 №4, 11 ноябрь 2021 №5, 12 ноябрь 2021 №6, 13 ноябрь 2021 №7 җыеннарда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 44 номерлы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары нигезендә Шушмабаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1 б йорт; ТР, Арча районы, Носы авылы, Татарстан урамы 45 йорт.

3. «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Шушмабаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 28 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ * ОГРН 1121690009143
ИНН 1609012607

*Шушмабаш авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*24 декабрь 2021ел, №38*
*карарына 1 нче кушымта*

**«Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 13 февраленә кадәр «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар;

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннарда билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7.Түләүләр физик затлар поручениесе буенча почта аша исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша күчерелә.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

*Шушмабаш авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*24 декабрь 2021ел, №38*
*карарына 2 нче кушымта*

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

«Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________________________
Адресы:________________________________________________________________
______________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
__________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № ______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
___________________________________________________________________________
бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«_________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел _____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*